# ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге Дружба торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2023 елның 17 ноябре №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел, № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел, №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2023 елның 17 ноябрендә сәгать 13.00 «2024 елда Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пункты территориясендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизация, контракт төзеп хэрби операциягә киткән һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 300 сум күләмендә җыярга һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы:

1) )Дружба торак пунктында коеларны ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Дружба торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм лампалар урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 38 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 28 кеше кертелгән.
Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
позиция өчен гражданнар җыенында катнашучы 28 кеше тавыш бирде; каршы позиция өчен _0 катнашучы тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар итте:

1. Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлегенең Дружба торак пунктында гражданнар җыены узды, гражданнар җыены нәтиҗәләре – гамәлдә.

2. Түбәндәге мәсьәлә буенча карарны таныргa: «2024 елда Сарман муниципаль районының Ләке авыл җирлеге Дружба торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә, I төркем инвалидлардан, хәрби хезмәт үтүче гражданнардан, мобилизация, контракт төзеп хэрби операциягә киткән һәм аларның гаилә

әгъзаларыннан, көндезге уку йортлары студентларыннан тыш, ризамы, һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга юнәлдерү:

1)Дружба торак пунктында коеларны ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү);

2) Дружба торак пунктында урам яктырту объектларын тоту һәм аларга хезмәт күрсәтү (энергия саклаучы яктырткычлар сатып алу һәм лампалар урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);

3. Халык җыены нәтиҗәләрен Ләке авыл җирлегенең информацион стендларында, Сарман муниципаль районының рәсми сайтында (http:// sarmanovo.tatarstan.ru хокукый мәгълүматның рәсми сайтында (httr://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 7 көн эчендә урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Сарман муниципаль районы Ләке авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Сарман муниципаль районы
Ләке авыл җирлеге башлыгы _ _ _ _ _ Ю.Г.Антонов.